**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 24 ноябрендәге 4117 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2023 елның 11 октябрендәге 3059 номерлы**
**«Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен раслау хакында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү турында**

Кадрлар үзгәрешенә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 11 октябрендәге 3059 номерлы «Махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен раслау хакында»гы карарының (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 27 октябрендәге 3247 номерлы, 2023 елның 15 ноябрендәге 3493 номерлы, 2023 елның 22 ноябрендәге 3611 номерлы, 2023 елның 1 декабрендәге 3783 номерлы, 2023 елның 19 декабрендәге 4158 номерлы, 2024 елның 26 гыйнварындагы 238 номерлы, 2024 елның 29 мартындагы 1222 номерлы, 2024 елның 1 июлендәге 2750 номерлы, 2024 елның 11 июлендәге 2969 номерлы, 2024 елның 2 ноябрендәге 4625 номерлы, 2025 елның 14 гыйнварындагы 29 номерлы, 2025 елның 27 мартындагы 904 номерлы, 2025 елның 19 маендагы 1542 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) 3 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. комиссия составыннан А.Ф.Сәгетдиновны чыгарырга;

1.2. комиссия составына комиссия әгъзасы сыйфатында Лихачева Яна Олеговнаны, Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе аппараты җитәкчесен кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевкә йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын**
**башкаручы – урынбасар** **И.В.Куляжев**